ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү сыйфатын яхшырту, аларны рәсмиләштергәндә бертөрлелекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү кагыйдәләрен расларга.
2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләгәндә әлеге кагыйдәләрдән файдаланырга тәкъдим итәргә.
3. «Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2005 елның 15 июнендәге 1383-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 15 сентябре
№ 1554-VI ДС